КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Югары Шытсу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

10.11.2025 №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 27 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып, «Сез 2026 нче елда Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Югары Шытсу торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 770,00 (җиде йөз җитмеш) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы»:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Югары Шытсу авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларындагы чокырларны вак таш салып ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- җир асты суларының табигый чыга торган урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Югары Шытсу торак пунктында чишмәгә будка төзү һәм янәшәдәге территориясен төзекләндерү) дигән сораулар буенча 2025 елның 10 ноябендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 221 кеше кертелгән, җыенда һәм тавыш бирүдә катнашучылар саны 119 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 119 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Югары Шытсу торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2026 нче елда Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Югары Шытсу торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 770,00 (җиде йөз җитмеш) сум күләмендә үзара салым кертүгә» һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Югары Шытсу авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларындагы чокырларны вак таш салып ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- җир асты суларының табигый чыга торган урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Югары Шытсу торак пунктында чишмәгә будка төзү һәм янәшәдәге территориясен төзекләндерү), карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shitsi адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Түбән Шытсу авыл
җирлеге башлыгы Б.М.Мәүлетов